# КАРАР

2021 елның 06 декабре № 36

**Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча үткәрелгән гражданнар җыены нәтиҗәсе турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 3 декабрендә 13.00 сәгатьтә һәм 2021 елның 3 декабердә 15.00 , 3 декабрендә 19:00 сәгатьтә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Әсән-Елга авылының Яр буе урамы юлларына вак таш җәю (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне тормышка ашыру; вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Әсән-Елга авылын яктырту өчен светодиод лампалар һәм махсус җиһазлар сатып алу;
- Әсән-Елга авылының урам юл челтәрен карап тоту ( килешү буенча эшләр өчен түләү);

Әсән-Елга авылында артезиан скважиналары өчен насослар сатып алу;

- янгын шланглары, гидрантлар, колонкалар сатып алу;
- чишмәләрне төзекләндерү һәм ремонтлау (вак таш җәю);
- асфальт сатып алу һәм Яшьләр урамына асфальт салу (проект-смета документларын эшләү һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Ø 500 ле корыч торбалар сатып алу, Әхмәт Юныс урамына вак таш җәю;
- Әсән-Елга авылының Әхмәт Юныс урамында су челтәрен ремонтлау, су башнясы сатып алу һәм урнаштыру, артезиан скважинасын китерү һәм урнаштыру (проект-смета документлары һәм килешү буенча эшләр өчен түләү);

-төзекләндерү (Әсән-Елга авылы исемен урнаштыру).

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены карары нигезендә: Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә **285** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны **148**.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен җыенда катнашкан 148 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлеге Әсән-Елга авылында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенының нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны: «I төркем инвалидлары, көндезге уку формасы буенча белем алучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 85 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Пычак авыл җирлегенең Әсән-Елга авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2022 елда үзара салымны 700 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

«РИЗА» «КАРШЫ»

кабул ителгән дип танырга.

3. Гражданнар җыенның нәтиҗәләрен мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Пычак авыл җирлеге башлыгы Г.Ш. Нәфыйков